**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№587**
**03.02.2023**

Башкарма комитетның «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2020 елның 19 маендагы 2314 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясының 7 өлеше, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.2 статьясы, Татарстан Республикасының «Балигъ булмаганнарга аерым товарлар сатуны чикләүне билгеләү өлешендә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 2 ноябрендәге 80-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2020 елның 19 маендагы 2314 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2020 елның 4 сентябрендәге 4734 номерлы, 2021 елның 27 маендагы 3591 номерлы, 2022 елның 10 мартындагы 1218 номерлы, 2022 елның 3 октябрендәге 5188 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта «1 нче, 2 нче кушымталарда» сүзләрен «1 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;

2) 1 нче кушымтада:

- исемдә «2.17» цифрларыннан соң «2.19, 2.20» цифрларын өстәргә;
- 1 пунктта «2.17» цифрларыннан соң «2.19, 2.20» цифрларын өстәргә;
- 2 пунктта «2.17» цифрларыннан соң «2.19, 2.20» цифрларын өстәргә;
- 4 пунктта «2.17» цифрларыннан соң «2.19, 2.20» цифрларын өстәргә;
- 5 пункт үз көчен югалткан дип таныргa;

3) 2 нче кушымта үз көчен югалткан дип таныргa;

4) 3 нче кушымтаны кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә.


2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы В.Х. Харисовка, Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы Э.Р. Фәттаховка, Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Ф.Ф. Хәбибуллинга, Башкарма комитетның административ-техник инспекция идарәсе башлыгы А.З. Хамматовка, Башкарма комитет карамагындагы җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсе башлыгы М.Х. Миннегалиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 3 февралендәге
587 номерлы карарына
кушымта

Башкарма комитетның
2020 елның 19 маендагы
2314 номерлы карарына
3 нче кушымта




Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева